Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының
Лагерка төп мәктәбе Гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе

| « Каралды » | «Килешенде » | « Раслыйм» |
|---|---|---|
| Укытучыларның МБ җитәкчесе<br>_____ / Мишкина И.В./<br>1 нче санлы беркетмә<br>« 26 » 08 2021 нче ел | Директор урынбасары :<br>_____ / Семенова С.Ю./<br><br>« 27 » 08 2021 нче ел | Лагерка төп мәктәбе директоры:<br>_____ / Майоров А.П./<br>Боерык № 145<br>« 28 » 08 2021 нче ел |

**ТАТАР ТЕЛЕННӘН**

**7 нче сыйныф өчен**

**ЭШ ПРОГРАММАСЫ**

2021-2022 нче уку елы

**Төзүче: Кармышов Фаиз Минагзамович**

*Педагогик совет утырышында гамәлгә керде*

*1 нче санлы беркетмә*

*“ 28 ” 08 2021 нче ел*

## Аңлатма язуы

**Эш программасы статусы**

Программа нигезенә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының, Рус мәктәпләрдәге рус төркеме укучыларына татар теленнән һәм татар әдәбиятыннан гомуми белем бирүнең дәүләт стандартлары салынды, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан расланган «Рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы» (Казан, 2013 нче ел), 7 нче сыйныф өчен Р.З. Хәйдәрова, Р.Л. Малафеева тарафыннан эшләнгән Татар теле (Казан, “Татармультфильм”нәшрияты 2014) дәреслегенә нигезләнеп төзелде. МБОУ “Лагерка төп гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет гомумбелем учреждениесенең 2021-2022 нче уку елына эш программалары турындагы положениесе. МБОУ “Лагерка төп гомуми белем бирү мәктәбе” нең 2021 – 2022 нче уку елына календарь укыту графигы.

7 нче сыйныфлар өчен татар теленнән эш программасы Россия Федерациясендәге һәм Татарстан Республикасындагы мәгарифкә кагылышлы хокукый-норматив актларга һәм федераль дәүләт стандартларына нигезләнеп төзелде:

1. Россия Федерациясенең “Мәгариф турында”гы Законы (Федеральный закон от 29.12.2012 273-ФЗ “Об образовании в Российской Федерации”).

2. Татарстан Республикасының “Мәгариф турында”гы Законы (Закон Республики Татарстан “Об образовании” № 68-ЗРТ от 22 июля 2013 года, статья 8).

3. Россия Федерациясенең “Россия Федерациясе халык телләре турында”гы 126-ФЗ нчы номерлы Законы (24.07.1998).

4. РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы приказы, 30 нчы август, 2013 нче ел №115 (“Об утверждении Порядка организации и осуществления образовательной деятельности по основным общеобразовательным программам – начального общего, основного общего и среднего общего образования”).

5. “Татарстан Республикасының халык телләре турында” Законы (Закон Республики Татарстан от 08.07.1992 № 1560-XII (ред. от 03.03.2012г.) “О государственных языках Республики Татарстан и других языках в Республике Татарстан”).

6. “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” Татарстан Республикасы Законы, 2004 нче ел, 1нче июль.

7. “2014-2020 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы”, 2013 нче ел, 25 нче октябрь, 794 нче карар.

8. Төп гомуми белем бирүнең Федераль дәүләт белем бирү стандарты (Россия Мәгариф һәм Фән министрлыгында 2010 нчы елның 17 нче декабрь боерыгы 1897 нче номер белән расланган, РФ Юстиция Министрлыгында 19644 нче регистрацион номеры белән 2011нче елның 1 нче февралендә теркәлгән).

9. Татарстан Республикасында 2012-2020 нче елларда фән һәм мәгариф үсеше турында “Дәүләт программасы”.

10. 2010-2015 нче елларда Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү стратегиясе “Киләчәк” программасы.

11. МБОУ “Лагерка төп гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет гомумбелем учреждениесенең 2021 -2022 нче уку елына эш программалары турындагы положениесе.

12. МБОУ “Лагерка төп гомуми белем бирү мәктәбе”нең 2021 – 2022 нче уку елына календарь укыту графигы.

7 нче сыйныф өчен "Татар теле " курсының эш программасы Федераль дәүләт белем бирү стандартларының таләпләренә туры китереп, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән Татарстан Республикасы Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән “Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту программасы”, (төзүче-авторлары: Р.З. Хәйдәрова, Р.Л. Малафеева. - Казан, 2014.)

Хәйдарова тарафыннан эшләнгән (Казан: “Татармультфильм”, 2014.) Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән дәреслеккә нигезләнеп төзелде.

Дәреслек: Татар теле. 7 сыйныф: рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек. – Казан: “Татармультфильм”, 2014.

**Рус балаларына татар телен укытуның төп максаты**

Рус балаларына татар телен укытуның төп максаты **-** гамәли максат: телне аралашу чарасы буларак үзләштерү өчен, укучыларга гаилә-көнкүрешкә, уку хезмәтенә бәйле сөйләм ситуацияләре кысаларында белем бирү һәм күнекмәләрен үстерү.

**Бурычлары:**

- Укучыларда татар сөйләмен тыңлап аңлау күнекмәләрен булдыру.

- Диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләрен үстерү.

- Дөрес язу һәм язма сөйләм күнекмәләрен булдыру.

- Төрле жанрдагы татар текстларын аңлап укуга өйрәтү.

- Татар теленең фонетик, орфоэпик, лексик, грамматик нигезләрен һәм үзенчәлекле тел күренешләрен гамәли үзләштерү.

- Татар теле дәресләрендә, белем бирү белән бергә, **тәрбияви бурычны** да үтәү мөһим.

- Аңа ирешү өчен, татар сөйләм этикеты үрнәкләрен кулланып, әңгәмә корырга, фикер йөртергә, хәбәр итәргә күнектерү.

- Татар дөньясына караган милли традицияләр, ризыклар, бәйрәмнәр, уеннар, халык авыз иҗаты үрнәкләре белән таныштыру һәм татар әдәбияты, сәнгате, мәдәнияте турында мәгълүмат җиткерү .

**Белем дәрәҗәсенә таләпләр:**

- сорауны формалаштыра белү һәм тулы җавап бирә белү;

- дәреслектә бирелгән тематик кысаларда татарчадан – русчага, русчадан – татарчага тәрҗемә итә белү;

- күчереп язу *(уку елы башында 60 сүзле текст (язма күләме – 60-65 сүз), уку елы ахырында 70 сүзле текст);*

- фикер йөртү элементлары кертеп, әзер план буенча бирелгән диалог, монолог язу

- изложение язу;

- эчтәлекне аңлап, тиешле тизлектә, дөрес уку: уку елы башында – 80-90 сүз; уку елы ахырында – 95-100 сүз;

**Күнекмәләргә таләпләр:**

Гомуми белем мәктәбендә татар теле дәресләре укучыларның сөйләм телен үстерүгә юнәлтелә, бу исә аларның **тыңлап аңлау, сөйләү һәм сөйләшү, уку, язу һәм язма сөйләм күнекмәләрен формалаштыруны** үз эченә ала.

- **тыңлап аңлау** – аерым авазларны, иҗек калыпларын, сүзләр, сүзтезмәләр, җөмләләрне, бәйләнешле текстларны ишетеп, мәгънәләрен һәм эчтәлекләрен аңларга өйрәтү;

- **диалогик сөйләмгә өйрәткәндә**, укучыларның көндәлек тормышын чагылдыра торган табигый темаларга сөйләшүләрен формалаштыру;

- **монологик сөйләмгә өйрәткәндә** аерым кешеләрне, әйберләрне табигать күренешләрен, хайваннарны тасвирлауга, сыйныф, мәктәп, авыл, шәһәр тормышы

һ. б. турында хәбәр итүгә, укылган (тыңланган) текстның эчтәлеген план буенча сөйләп бирү күнекмәләрен формалаштыру;

- **укуга өйрәткәндә**, татар хәрефләрен танып, алар белдергән авазларны дөрес әйтү, дәреслектәге текстларны сәнгатьле итеп, йөгерек һәм аңлап уку күнекмәләре булдыру;

- яңа сүзләрне сүзлектән табу;

- **язуга өйрәткәндә,** сүзләрне иҗекләргә бүлеп, юлдан юлга дөрес күчерү кагыйдәләрен үзләштерү, сөйләмдә актив кулланыла торган сүзләрне орфографик дөрес язу күнекмәләрен үстерү;

- **язма сөйләмгә өйрәткәндә**, терәк сүзләр, сүзтезмәләр һәм үрнәк җөмләләргә нигезләнеп, өйрәнелә торган лексик тема яки бирелгән ситуация буенча җөмләләр яза белү.

Укучыларда **фонетик күнекмәләр** булдыру өчен, түбәндәгеләргә игътибар итү мөһим: татар теленә генә хас булган авазларның әйтелешен үзләштерү; татар һәм рус телләрендә уртак булган, ләкин әйтелешләре белән аерылган авазларны чагыштырып өйрәнү; авазларны сүзләрдә, сүзтезмәләрдә, җөмләләрдә, бәйләнешле сөйләмдә дөрес әйтүгә ирешү. Бу төр күнекмәләр булдыру өстендә эзлекле эшләү генә укучыларның сөйләмендәге фонетик хаталарны бетерергә мөмкинлек бирә.

Укучыларның **лексик күнекмәләрен** үстерү өчен, сүзләрнең әйтелешен, язылышын, мәгънәсен, ясалышын, башка сүзләр белән бәйләнешен, сөйләмдә кулланышын үзләштерү шарт. Моның белән беррәттән, татар һәм рус сүзләрнең мәгънә ягыннан аермаларын күрсәтеп бару да, рус телендә эквивалентлары булмаган сүзләрне аңлатып бирү дә сорала.

Укучыларның **грамматик күнекмәләрен** үстерү – төрле сүз төркемнәренең морфологик формалары, ясалышлары белән таныштыру, сүзләрнең җөмләдә үзара бәйләнеш чараларын үзләштерү һәм кагыйдәләрен белү дигән сүз. Татар телен икенче тел буларак укытканда, лексик-грамматик материалны синтаксик нигездә үзләштерү принцибына таянып эш итү кирәк, чөнки сүзләр башка сүзләр белән бәйләнештә булганда гына, җөмлә, гомумән, сөйләм барлыкка килә.

**Укыту фәненең уку планында тоткан урыны**

7 нче сыйныфта телне гамәли үзләштерү нәтиҗәсендә укучыларда татар теленең күп мәдәниятле дөньядагы роле һәм мөһимлеге турында күзаллаулар формалаша. Татар мәдәниятенең укучылар өчен булган катламы белән танышу башка мәдәниятләргә карата ихтирам хисе уята, укучыларга үз мәдәниятләрен дә тирәнрәк аңларга һәм объектив бәяләргә мөмкинлек бирә.

Укыту планында каралганча, татар теле дәресләре өчен эш программасы атнага 1 сәгать исәбеннән, елга 35 сәгатькә төзелде.

**Укытуның көтелгән нәтиҗәләре**

**Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр:**

- шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру;

- әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;

- әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомумкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;

- “гаилә”, “туган ил”, “мәрхәмәтлелек”, төшенчәләрен кабул итү, укучыда “башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык”, “кеше кадерен белү” кебек хисләр формалашу.

**Метапредмет нәтиҗәләре:**

Төп гомуми белем бирү баскычында татар теле һәм әдәбиятын укыту, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук, реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен (танып белү, регулятив, коммуникатив) формалаштыруга хезмәт итә.

Укучыларда мәгълүмати җәмгыятьтә яшәү һәм эшләү өчен кирәкле күнекмәләр үстерелә. Укучылар текст, күрмә-график рәсемнәр, хәрәкәтле яисә хәрәкәтсез сурәтләр, ягъни төрле коммуникацион технологияләр аша тапшырыла торган мәгълүмати объектлар белән эшләү тәҗрибәсе ала; презентацион материаллар әзерләп, зур булмаган аудитория алдында чыгыш ясарга өйрән*ә; у*кучыларда, компьютер яисә МКТнең башка чаралары белән эш иткәндә, сәламәтлеккә зыян китерми торган эш алымнарын куллана алу күнекмәләре формалаша.

**Танып-белү гамәлләре:**

- фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;

- иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру;

- объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү;

- төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;

- тиешле мәгълүматны табу өчен, энциклопедия, белешмәләр, сүзлекләр, электрон ресурслар куллану.

**Регулятив гамәлләр:**

- дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли һәм алар белән дөрес эш итә белү;

- дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү;

- уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү;

- эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;

- уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү;

- билгеләгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү;

- укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый һәм, кирәк булганда, төзәтмәләр кертә белү;

- ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру.

**Коммуникатив гамәлләр:**

- әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү;

- әңгәмәдәшең белән аралашу калыбын төзү;

- аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хисслелек, эмпатия хисләре);

- парларда һәм күмәк эшли белү;

- мәгълүматны туплау өчен, күмәк эшчәнлектә катнашу;

- әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү.

**Предмет нәтиҗәләре**:

- укучыларның коммуникатив компетенциясен (аралашу осталыгын) үстерү, ягъни татар телендә сөйләшүчеләр белән телдән яки язмача аралашу күнекмәләре булдыру;

- коммуникатив бурычлар куя һәм хәл итә белү, адекват рәвештә арашуның вербаль һәм вербаль булмаган чараларыннан, сөйләм этикеты үрнәкләреннән файдалана алу, итагатьле һәм киң күңелле әңгәмәдәш булу;

- “Татар теле һәм әдәбияты” предметына карата уңай мотивация һәм тотрыклы кызыксыну булдыру һәм шулар нигезендә белем алуның алдагы баскычларында татар телен уңышлы үзләштергә шартлар тудыру.

**Үзләштерелергә тиешле грамматик материал**

1. Хәл фигыльнең 4 нче формасы (-ганчы/-гәнче, -канчы/-кәнче) белән таныштыру; -ып,-еп, -п;-гач/-гәч,-кач/-кәч формаларын сөйләмдә куллану.

2. Исем фигыль формасы белән таныштыру .

3. Кушма, парлы, тезмә исемнәрнең ясалышы,аларны сөйләмдә куллану.

4.Сыйфат фигыльнең хәзерге һәм үткән заман формалары белән таныштыру.

5. Рәвеш төркемчәләре белән таныштыру, сөйләмдә куллану.

6. Синоним һәм антоним сүзләрне сөйләмдә куллану.

7.Тезүче (һәм, да/дә, әмма, яки) һәм ияртүче (әгәр, шуңа күрә) теркәгечләрне сөйләмдә куллану.

8. Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен билгеләргә өйрәтү.

**Татар теленнән контроль һәм практик эшләр.**

| Фән | Сыйныф | Контроль эш | Мөстәкыйль эш | Күчереп язу | Сүзлек диктанты | Контроль диктант |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Татар теле | 7 | 3 | - | - | - | 1 |

**Укытуның материаль-техник һәм мәгълүмати тәэмин ителеше**

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан расланган “Рус мәктәпләрендәге рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен һәм әдәбиятын укыту гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты”.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән “Төп гомуми белем бирү мәктәбенең рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен һәм әдәбиятын коммуникатив технология нигезендә укыту программасы”, төзүче-авторлары: Р.З. Хәйдәрова, Р.Л. Малафеева. – Казан, 2014.

3. Хәйдәрова Р.З., Гыйниятуллина Л.Ә. Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларында татар теле укыту. 6 нчы сыйныф (Укытучылар өчен методик кулланма). – Казан, “Татармультфильм”, 2014.

4. Хәйдәрова Р.З., Әхмәтҗанова Г.М. Гомуми белем бирү оешмаларында рус телле балаларның татар теленнән белемнәрен контрольгә алу буенча биремнәр җыентыгы. – Яр Чаллы, 2014.

5. Харисов Ф.Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. – Казан, “Мәгариф”, 2008.

**Өстәмә әдәбият**

1. Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле укыту, 7 нче сыйныф. Авторлары: Р.З.Хәйдәрова, Р.Л. Малафеева – Казан, “Татармультфильм”, 2014.

2. Фатыйхова Р.Н. Татар теленнән диктантлар, контроль эшләр, тестлар. – Казан, “Гыйлем” нәшрияты, 2009.

3. Насибуллина Р.Н. “Татарский язык в таблицах и схемах для русскоязычных учащихся начальных классов”. – “Мәгариф” нәшрияты, 2007.

4. Максимов Н.В. “Урта мәктәптә татар теле укыту: Фонетика. Морфология.”Укытучылар өчен методик кулланма. – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2004.

5. “Фән һәм мәктәп”, “Мәгариф” журналлары, “Мәгърифәт”, “Ачык дәрес” газеталары.

**Мәгълүмат чыганаклары**
http://www.ed.gov.ru

Белем бирү буенча федераль агентлык
http://www.apkppro.ru РФ мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм профессиональ әзерләү академиясе
http://www.lexed.ru Федеральный центр образовательного законодательства
http://www.rustest.ru Федераль тест үткәрү үзәге
http://www. tatedu.ru ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы
http://www.edu. kzn.ru ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы Белем порталы
http://www.mon.tatar.ru
http://www.shoolexpo.ru
http://. belem.ru
http://. tatar.ru ТР рәсми серверы
http://. Tat. Tatar - inform.ru ТР мәгълүмат агентлыгы
http://. intertat.ru ТР электрон газетасы
http://. xat.ru Татар хат алышу хезмәте
http://. suzlek.ru on- line русча сүзлек
http://. Kitapxane.at.ru татар телендәге әдәби әсәрләр китапханәсе
http://. Tatar.com.ru татар теле сүзлекләр һәм үзәйрәткечләр
http://. Tatarca.boom.ru татарча текстлар
http://. tataroved.ru Татар тарихы: төрки – татар дөньясы
http://. selet.ru “Сәләт” яшьләр
http://. Kitapxane.at.ru татар телендәге әдәби

**Календарь – тематик планлаштыру**

| № | Дәрес темасы | Укучылар эшчәнлегенә характеристика яки уку эшчәнлеге төрләре | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|
| | | | план буенча | фактик үтәлеш |
| 1 | 1 сентябрь – белем бәйрәме | Яңа уку елына әзерлек,нәрсәләр алулары турында сөйли белү | | |
| 2 | Җәйге каникуллар ничек үтте? | Рәсемнәргә карап тиешле сүзләрне кулланып диалог төзи алу | | |
| 3 | Хәл фигыль | Җөмләләрдә хәл фигыльне таба белү | | |
| 4 | Боерык фигыль | Боерык фигыльләрне искә төшерү һәм аларны сөйләмдә куллана белү | | |
| 5 | З.Туфайлова “Самат” шигырендәге лексик-грамматик материал | Сүзлек белән эшли белү | | |
| 6 | Рәвеш | Җөмләләрдә рәвешләрне таба белү һәм җөмләләр төзүдә куллану | | |
| 7 | Сүзләргә кушымчалар ялгау тәртибе | Сүзләргә кушымчалар ялгау тәртибен белү | | |
| 8 | Контроль эш | Укучыларның белем дәрәҗәсен тикшерү | | |
| 9 | Хаталар өстендә эш | Сүзләрнең дөрес язылышын, әйтелешен төзәтү | | |
| 10 | Ш.Маннур “Киңәш” шигырендәге лексик-грамматик материал | Сүзлек белән эшли белү | | |
| 11 | “Белем һәм тормыш” бүлеген кабатлау дәресе | Укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү | | |
| 12 | Сыйфат фигыль | Сыйфат фигыльләрне җөмләдә куллана белү | | |
| 13 | Җөмләнең баш кисәкләре | Җөмләләрдә ия белән хәбәрне таба белү | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 14 | Теркәгечләр | Тезүче һәм ияртүче теркәгечләрне истә калдыру һәм куллана белү | | |
| 15 | Исем фигыль | Исем фигыльләрне табу һәм аның формасын куллана белү | | |
| 16 | Контроль эш  “Без Татарстанда яшибез” | Укучыларның белемен тикшерү | | |
| 17 | Хаталар өстендә эш | Сүзләрнең дөрес язылышын истә калдыру | | |
| 18 | “Без бергә ял итәбез” бүлеген кабатлау дәресе | | | |
| 19 | Иярчен кисәкләр. Аергыч | Кагыйдәне белү, дәреслек һәм сүзлек белән эшли алу | | |
| 20 | Иярчен кисәкләр. Тәмамлык | Кагыйдәне белү, җөмләләрдән тәмамлыкларны таба белү | | |
| 21 | Иярчен кисәкләр. Хәл | Сүзләрдән җөмләләр төзү. Җөмләнең иярчен кисәге-хәлне танып белүгә ирешү | | |
| 22 | Хәлләрнең җөмләдә кулланылышы | Хәлләрне җөмләдә куллана белү | | |
| 23 | Кисәкчәләр | Кисәкчәләрне җөмләләрдә таба һәм алар белән җөмләләр төзи белү | | |
| 24 | Диктант. “Минем энем” | Укучыларның дөрес язу осталыгын тикшерү | | |
| 25 | Хаталар өстендә эш | Сүзләрнең дөрес язылышын истә калдыру | | |
| 26 | Өлкәннәр һәм кечкенәләр” бүлеген кабатлау дәресе | Укучыларның белемнәрен  тирәнәйтү | | |
| 27 | Туган ягым - Татарстан | Укучыларны белгәннәренә таянып, хикәя төзергә һәм дәлилли белергә өйрәтү | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 28 | Татарстан Республикасы турында сөйләшү | Сорауларга җавап бирә белү.Җөмләләрне киңәйтеп яза алу | | |
| 29 | Теләк фигыль | Теләк фигыльләрне танып белү, дөрес куллану | | |
| 30 | Теләк фигыльнең җөмләдә кулланылышы | Рус теленә тәрҗемә итү күнекмәләрен булдыру | | |
| 31 | “Без Татарстанда яшибез” бүлеген кабатлау дәресе | Укучыларның белемнәрен тирәнәйтү | | |
| 32 | БСҮ дәресе | Диалоглар һәм монологлар төзеп сөйләшә алу | | |
| 33 | Контроль эш. “Без Татарстанда яшибез” | Укучыларның белемнәрен тикшерү | | |
| 34 | Хаталар өстендә эш | Сүзләрнең дөрес язылышын истә калдыру | | |
| 35 | Үткәннәрне кабатлау дәресе | Укучыларның белем дәрәҗәсен тикшерү | | |